| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октября 2023 г. №88

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (ижтимагый фикер алышулар) уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

28.09.2023 елның №02-08-01-2023/Прдп316-23-20920011 номерлы "Гавами тыңлаулар (ижтимагый фикер алышулар) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы карарга карата протестка таянып, "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" һәм "России Федерациясендә тимер юл транспорты турында" Федераль Законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында" 29.12.2022 елның 612 номерлы Федераль Законга нигезләнеп, Югары Субаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Югары Субаш авыл җирлеге Советының 28.05.2020 елның 138 номерлы карары белән расланган (29.06.2022 елның 52 номерлы карарындагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) гавами тыңлаулар (ижтимагый фикер алышулар) уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 3 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 нче пунктча өстәргә:

4) генераль планнар проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проекты, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, күрсәтелгән документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, Шәһәр төзелеше Кодексы һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш.

1.2.Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 13 нче статья өстәргә:

13 статья. Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын, гавами тыңлауларны карау үзенчәлекләре.

Генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларына, территорияне планлаштыру проектларына, территорияне ызанлау проектларына, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектларына кагылышлы мәсьәләләр, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектларга, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карарлар проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирүче проектларга, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртүгә караган мәсьәләләр, җирләрдән файдалануның расланган кагыйдәләре булмаганда, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән нигезләмәләрне исәпкә алып,шулай ук ижтимагый фикер алышуларда каралырга мөмкин.

Җирлекләрнең генераль планнары проектлары буенча ижтимагый фикер алышуларны, гавами тынлауларны оештыру һәм уздыру үзенчәлекләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсендә китерелгән.

Генераль план проекты буенча һәм җирлекләрнең генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча ижтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар мәҗбүри тәртиптә үткәрелә (алга таба – ижтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар).

Ижтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздырганда, анда катнашучыларны бертигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатында, Югары Субаш авыл Советы территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

Җәмәгать фикер алышуларын яки гавами тыңлауларны үткәрү вакыты, җирлек халкына аларны үткәрү турында хәбәр ителгәннән алып, җәмәгать фикер алышулары яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында нәтиҗә басылган көнгә кадәр, җирлек уставы яки җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да ким булмаска тиеш.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә (комиссия рәисе Мөхәммәтгалиев Р.Н.).

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы А.А.Хөснетдинов